ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ БОГАДЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

423763, Иске Богадыа вылы, Үзәк ур., 60нчыйорт.
Тел.:(85552)5-45-30; факс:5-45-30;
E-mail: sbuq-akt@yandex.ru

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА СТАРОБУГАДИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА

423763, село Старые Бугады,
ул. Центральная, дом 60.
Тел.:(85552)5-45-30; факс:5-45-30;
E-mail: sbuq-akt@yandex.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«02» ноября 2020 года** **№ 2**

Актаныш муниципаль районы Иске Богады, Яңа Җияш, Иске Солтангол, Югары Богады, Иске Богады авыл җирлеге Каенлык авылларында халык җыены үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Актаныш муниципаль районы «Иске Богады авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 25.1 статьясы, Иске Богады авыл җирлеге башлыгы:

КАРАР БИРӘ:

1.Актаныш муниципаль районы Иске Богады авыл җирлеге Иске Солтангул авыл территориясендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча 2020 елның 20 ноябрендә сәгать 8.00гә гражданнар җыенын билгеләргә.

2. 2020 елның 20 ноябрендә сәгать 10: 00 Актаныш муниципаль районы Иске Богады авыл җирлегенең Яңа Җияш авылы территориясендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

3. 2020 елның 20 ноябрендә сәгать 13.00гә Актаныш муниципаль районы Иске Богады авыл җирлеге Югары Богады, Каенлык авыл территориясендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

4. 2020 елның 23 ноябрендә сәгать 14.00 Актаныш муниципаль районы Иске Богады авыл җирлеге Иске Богады авылы территориясендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2021 елда үзара салым түләүләренең бер тапкыр 18 яшькә җиткән һәр граждандан 500 (биш йөз) сум күләмендә кертелүенә, аларның яшәү урыны, җирле референдумда катнашуларына һәм тавыш бирүдә катнашуларына бәйсез рәвештә, Бөек Ватан сугышы ветераннары, көндезге формада белем алучы студентлардан, 1 Төркем инвалидларыннан тыш, җирлек чикләрендә теркәлгән

һәр граждандан 500 (биш йөз) сум күләмендә акча кертү белән килешәсезме?, - түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү:

1.- Ритуаль хезмәт күрсәтүне оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту: - җирләү урыннарын документаль рәсмиләштерү; - зират коймасын ремонтлау; - ритуаль хезмәтләр өчен инвентарь алу;
2. Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:
- җирлек торак пунктларында хуҗасыз объектларны сүтү, хуҗасыз территорияләрне ремонтлау һәм коймалар кую.;
- авыл җирлеге территориясендә агач кисү;
- торак пунктлардагы урам исемнәре һәм йорт номерлары язылган күрсәткечләрне әзерләү һәм урнаштыру;

3. Массакүләм ял итү урыннарын төзекләндерү һәм карап тоту:

- авыл җирлегендә яшәүчеләрнең массакүләм ял итү өчен шартлар тудыру, аларны төзекләндерү, коймалар белән тәэмин итү;
4. Автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
- юлларны ремонтлау һәм карап тоту (ПГС салу, грейдерлау, кардан чистарту);
5. Җирлек чикләрендә Халыкны электр белән тәэмин итү һәм су белән тәэмин итү:
- урамнарны яктырту электр челтәрләрен карап тоту;
- су челтәрләрен һәм чишмәләрне ремонтлау, карап тоту, су чыганакларын лицензияләү, документаль рәсмиләштерү.

« ӘЙЕ» « ЮК»

1..Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Актаныш районы, Иске Солтангул авылы, Үзәк урамы, 42 нче йорт.
2.Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Актаныш районы, Яңа Җияш авылы, Г.Тукай урамы, 7 нче йорт.

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Актаныш районы, Югары Богады авылы, Урман урамы, 20 йорт.

4. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Актаныш районы, Иске Богады авылы, Узәк урамы, 60 йорт.

5.Җыенны Актаныш муниципаль районы Иске Богады авыл җирлеге башкарма комитеты оештыра.

6. Әлеге карарны Иске Богады авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында халыкка җиткерергә.

7. Үтәлешне контрольдә тотам.

Иске Богады авыл җирлеге башлыгы И.Ф.Фаттахов.